**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 5 декабрендәге 5029 номерлы карары**

**2025 елда Казан шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан муниципаль парковкалар (парковка урыннары) эше турында**

2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы федераль законга, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 30 декабрендәге 7660 номерлы «Казан шәһәренең җирле әһәмияткә ия булган гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан муниципаль парковкалар булдыру турында»гы карарына (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), Россия Федерациясенең Хезмәт кодексына таянып, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 4 октябрендәге 1335 номерлы «2025 елда ял көннәрен күчерү турында»гы карары, 1992 елның 19 февралендәге 1448-XII номерлы «Татарстан Республикасының бәйрәм һәм истәлекле даталары турында»гы Татарстан Республикасының Законы (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) нигезендә:

**1. Карар бирәм:**

1.1. 2025 елда Казан шәһәренең җирле әһәмияткә ия булган гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан түләүле муниципаль парковкаларның (парковка урыннарының) түбәндәге бәйрәм һәм бәйрәмнәрне күчерүгә бәйле ял көннәрендә транспорт чараларын куйган өчен түләү алмый торган түбәндәге эш режимын билгеләргә: 1-3, 6-8 гыйнвар; 1, 2, 8, 9 май; 12, 13 июнь; 3, 4, 6 ноябрь; 31 декабрь; Ураза бәйрәме; Корбан бәйрәме. Ай календаре һәм гадәткә кергән традицияләр нигезендә Ураза бәйрәмен һәм Корбан гаетен

үткәрү көннәренә туры килә торган көннәр Татарстан Республикасы Рәисе Указы белән билгеләнә;

1.2. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. Казан шәһәре Думасы аппаратының мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) юл хәрәкәтендә катнашучыларга әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән ял көннәрендә Казан шәһәренең җирле әһәмияткә ия булган гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан муниципаль парковкаларның (парковка урыннарының) түләүсез эш режимын кертүне массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә **тәкъдим итәм**.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**